**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3874**
**12.05.2023**

Башкарма комитетның 2022 елның 9 августындагы 4004 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре өстендә авиация эшләре, парашютта сикерү, һава судноларының демонстрацион очышлары, пилотсыз һава судноларының очышлары (максималь очыш массасы 0,25 килограммнан ким булган пилотсыз һава судноларының очышларыннан тыш), бәйләп куела торган аэростатларны күтәрү, шулай ук алар хакында белешмәләр аэронавигация мәгълүматлары документларында бастырып чыгарылмаган Яр Чаллы шәһәре чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга төшү (очып китү) өчен рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы Карарының 1 пунктының «а» пунктчасы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 9 августындагы 4004 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре өстендә авиация эшләре, парашютта сикерү, һава судноларының демонстрацион очышлары, пилотсыз һава судноларының очышлары (максималь очыш массасы 0,25 килограммнан ким булган пилотсыз һава судноларының очышларыннан тыш), бәйләп куела торган аэростатларны күтәрү, шулай ук алар хакында белешмәләр аэронавигация мәгълүматлары документларында бастырып чыгарылмаган Яр Чаллы шәһәре чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга төшү (очып китү) өчен рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 3.3.2.1 пунктына, унберенче абзацны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Формалаштырылган запросны формат-логик тикшерү, орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, гариза бирүче тарафыннан запросның электрон формасының һәр кырын тутыру процессында, бердәм портал тарафыннан автомат

рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал, запросның электрон формасының дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, турыдан-туры запросның электрон формасында мәгълүмати хәбәр аша, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов